# Портфолио

## Рамазанова Чулпан Фоат кызы






pedsovet.su

МБГБУ «Куныр урта гомуми белем бирү мәктәбе”





*Туган көне:* ***15 нче июль, 2007нче ел.***

*2014- 2016 аралыгы*

1209004896@edu.tatar.ru

***2 нче сыйныф***

# Үзем турында

Мин, Рамазанова Чулпан Фуат кызы,
2007 нче елның 15 нче июлендә Балтач
районы Куныр авылында туганмын. Без
гаиләдә 2 бала. Энем Илнур өчен мин яраткан
апа.

1 яшь тә 7 айдан „Карлыгач" балалар
бакчасына йөри башлаганмын. 2014 елда
Куныр урта мәктәбенең 1 нче сыйныфына
укырга кердем. Без 1 нче сыйныфта 3 укучы
идек, 2 нче сыйныфка Дорга авылыннан
тагын 3 укучы килде. Шулай итеп, сыйныфыбызда
3 кыз, 3 малай булдык. Мине сыйныфта командир
итеп сайладылар. Бу бик җаваплы вазифа,
укытучының уң кулы, ярдәмчесе. Мин иптәш-
ләремә дә һәр эштә ярдәм итәргә тырышам.
Укуда да сынатмыйм, чирекләрдә гел 5 ле.














# Сәлам, бу –без !!!

## Рамазановлар без!

Без Кунър авылының иң күркәм гаиләләренең берсе Рамазановлар гаиләсе. Әти-әниемнең хезмәт сөючәнлекләре белән уңышка ирешеп яшәүләре кешеләргә үрнәк.

Әтиебез Рамазанов Рәфат Гарифҗан улы гаиләдә 3нче бала. Язмышын туган авылы белән бәйләгән. Әтиебез тормышын төзелеш эшенә багышлаган. „Кулыннан гөлләр тама!"– дип әйтергә була аның турында. Үз куллары белән, туганнары ярдәмендә, бик матур йорт төзеп чыктык.

Әниебез Айсылу да Кунър авылыннан. Пар тормыш корып яшәүләренә 10 ел була. Әниебез күрше Дәрга балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Энем Әнир балалар бакчасына йөри. Әти белән бергә эшләргә өйрәнә. Үзем Кунър урта мәктәбенең 2нче сыйныфында белем алам. 5ле һәм 4ле билгеләренә генә укыйм. Әти-әниемнең иң зур ярдәмчесе.

Өйдәге һәр эшне киңәшләшеп эшлибез. Әнә шулай киңәшләшеп эшләгәнгә күрә, гаиләбез нигезе дә һәрвакыт нык.






**Рамазановлар гаиләсенең
туган көне
2006 нчы ел**

*Гомер юлларыгыз озын булсын!
Тигез томыш аны бизәсен!
Яшәү дәвере якты көннәр
бирсен,
Авырлыклар мәңге килмәсен!*



# Әтиебез Фоат

*“Әткәгез”,- диеп һәрвакыт*
*Сүз башлады әнкәем.*
*Бөтенебез шулай сиңа*
*Сыендык без, әткәем.*

*Җил-давылдан ышыкладың*
*Җаның-канатың белән.*
*Йөрәкләргә көч өстәдең*
*Җылы карашың белән.*

*Ал димәдең, ял димәдең,*
*Безнең өчен тырыштың.*
*Син өйрәттең бит җиңәргә*
*Авырлыгын тормышның.*

*Сукмасаң да, курыктык без,*
*Һәм ихластан ярattык!*
*Әткәйгә әйтәм алайса, дип,*
*Бер-беребезне тыңлаттык.*

*И әткәем, бәгырькәем,*
*Синсез ямь юк һичләр дә.*
*Мең яшә син, тал чыбыгың*
*Торсын, торсын киштәдә!*



Көннәр буе йөгерсәм дә,
Мин армыйм.
Уку авыр булса булсын –
Зарланмыйм.
Орышсаң да кайвакытта
Еламыйм ич.
Син шат булсаң, тора алмыйм
Елмаймый һич.
Исәнлек-саулыгың сорап,
Дога кылам:
Әниемнән аермасын
Берүк ходам!

*Әниебез Айсылу*




# *Әбиебез Зөлхия*

Дәү әни караган мине
Әнием эштә чакта.
Ашаткан ул, сөт эчергән,
Бергә уйнаган хәтта.

Юындырган, киендергән,
Йөрегән күтәреп тә.
Әкиятләр дә сөйләгән.
Йоклаткан тирбәтеп тә…

Дөньяда иң жылы әби
Безнең әби, беләбез.
Шуңа күрә энем белән
Куенына керәбез







Энем белән икебез
Белем алып мәктәптә
Чын кеше булып үсәргә
Телибез киләчәктә.

# Кечкенә җиңүебез

- Сыйныф җитәкчебез Лилия Нургаязовна “Гаилә “ бәйрәмендә катнашырга дигәч, бераз куркып калдык. Чөнки әтиебез Фоатның бер дә сәхнәгә чыкканы юк. Шулай да, барлык көчебезне куеп, бу кичәгә әзерләндек. Сәхнәгә, тамашачы алдына чыгу бик җаваплы эш.
- Ә тамашачы бик җылы каршы алды үзебезне. Зал гөрләп кул чапты.
- “Алтын куллы “ гаилә номинациясендә җиңү яулау безнең өчен бик зур шатлык.
- Сезнең ихтибарга бәйрәмнең язмасын тәкъдим итәм




# Туган авылым Куныр

Элек Кубыр елгасы буенда “Кугынур” дигән мари авылы булган. Ул “киң кыр” дигәнне аңлата. Аннан авылга татарлар килә башлаган. Марилар күчеп киткәннәр. Авыл исемен татарлаштырып “Куныр” дип үзгәрткәннәр.

Хәзерге вакытта Куныр авылы районыбызның иң төзек, иң бай авылларының берсе. Авылыбызда **827** кеше яши, **227**хуҗалык бар.

Туган авылымны бик яратам, анда яшәвем белән горурланам.

Авылымның кышкы күренешен сезгә тәкъдим итәм. Әле бу авылның барлык йортлары да түгел. Авылым һәр ел фасылында да бик матур.



# Шөгыльләрем

Үзем бик тә тиктормас бала. Һәр әйберне беләсем килә. Дәрес вакытында укытучылар өстәмә бирем яудыралар гына, чөнки иптәшләремнән күпкә алда эшләп барам. Кызулыгым кайвакыт комачау итсә дә, апам яңа үрләргә үсендереп тора.

Шуңа күрә дәрестән тыш үткәрелгән түгәрәкләргә дә бик теләп йөрим, чөнки үземне кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап алам.

Илсөяр Камаловна, Радик Фердинандович, Гөлнара Ханнановна, Рәдиф Вәлиуллович үткәргән түгәрәкләр бик җанлы үтә.

Гел хәрәктләнергә яраткач волейбол секциясенә дә язылдым. Әле яңа өйрәнеп киләм. Киләчәктә ярышларга да йөрермен, җиңүләр дә яулармын.









Эшли-эшли өйрәнәм.





# Мәктәбем минем

320 урынга исәпләнгән урта мәктәп бинасы 1980нче елда ишекләрен ача.

Хәзерге вакытта мәктәбебезгә 3 авылдан килеп 114 бала белем ала.


Аларга 27 укытучы белем һәм тәрбия бирә.

2015 нче елда мәктәбебезгә капиталь ремонт ясалды. Ул хәзер күз явын алырлык матур. Көн саен мәктәпкә ашкынып киләбез. Мәктәбебез якты, чиста, зәвыклы итеп эшләнгән. Мондый мәктәп бер бездә генәдер. Шушы мәктәптә укуым белән горурланам.

Укытучыларны бик хөрмәт итәбез. Алар безгә бар көчләрен куеп белем бирә. Ә безгә бары тик тырышып укырга, иренмәскә генә кала.



# Яраткан укытучыларым



Рәсем, технология укытучысы, түгәрәк җитәкчесе



Сыйныф җитәкчебез



Инглиз теле укытучысы




Театр түгәрге җитәкчесе



Физкультура укытуч



Түгәрәк  җитәкчесе

# Яраткан фәннәрем

- Миңа барлык фәннәр дә бик ошый.
- Әйләнә- тирә дөнья дәресе аеруча кызыклы. Анда үсемлекләр, хайваннар һәм башка бик күп төрле табигать серләре белән танышабыз. Күзәтүләр оештырабыз, кечкенә булса да ачышлар ясыйбыз.
- Математика дәресен яратам. Аңлатмалар, мәсьәләләр, кызыклы биремнәр үтим. Бу фәнне аеруча көтеп алам. АпабыУчи.ру сайты белән таныштырды. Анда математика буенча белемнәрне тагын да камилләштерергә була. Сыйныфыбыз белән кызыксынып эшләдек. Олимпиадаларын уңышлы үтәп килә. 2 нче сыйныфлар өчен булган биремнәрне инде декабрь аенда ук эшләп бетердем. Лаборатория биремнәрен эшлим.
- Музыка фәнен дә якын күрәбез, чөнки үзебез белмәгән музыкаль төшенчәләрне өйрәнәбез. Үзем бик теләп җырлыйм, биим.

Рәсем дәресен көтеп алам. Чөнки кечкенә вакытта әнинең кәгазьләренә гел рәсем ясый идем. Хәзер бик теләп рәсем конкурсларында катнашам. Рәсем ясаганда ничектер миңа рәхәт, тыныч. Радик Фердинандович түгәрәк оештыргач бик теләп язылдым.

Ә физкультура дәресе көн саен булсын иде. Гел хәрәкәттә булырга яратам. Дәрестә ниләр генә эшләмибез. Йөгерәбез, сикерәбез, чаңгы шуабыз, тимераякта ярышабыз, волейбол, баскетбол уйныйбыз. Ленар Билсурович төрле ярышлар уздыра.

Технология дәресе дә ошый. Үз кулың белән нидер ясау бик кызыклы Эшләнмәләребездән күргәзмәләр оештырабыз. Аз гына булса да мактанышып алабыз.

Миңа һәр фән дә бик ошый. Алар барысы дә бик кирәкле, һәрберсендә яңа бәлемнәр, күнекмәләр аласың. Алга таба бер урында туктап калмыйча, яхшы укысам иде.

Безне, үзенең укучыларын белемле булсын дип Лилия апабыз бөтен көчен куя.

# Җәмәгать эшчәнлегем

Дәреслэрдән соң үткәрелгән чараларда сыйныфыбыз белән бик теләп катнашабыз. “Белем бәйрәме”, “Сөмбелә”, “Әниләр көне”, “Яңа ел”, “Гаилә бәйрәм”нәре бик нык оешканлык белән үтә.

Мәктәбебездә укучылар өчен конкурслар һәрдаим булып тора. Алар зур әзерлек белән үтә.

1 нче сыйныфта укыганда “Мәдәни көндәлекне” бик теләп тутырдым. Аның өчен гаиләбез белән экскурсияләргә йөрдек.

Яңа ел бәйрәменә дә ныклап әзерләндек. Ел саен карнавал костюмнары тегәбез. Төрле концерт номерлары әзерлибез.

Патриотик җырлар конкурсында беренче мәртәбә катнашсак та, кызыклы булды.

Сыйныфыбыз командиры булгач, рапорт бирдем, әйдәүче булдым.














Яңа ел-2015


Яңа ел-2016



Гаилә бәйрәме



Сөмбелә-2015


Әлифба бәйрәме




Сөмбелә-2014


Әлифба бәйрәме

# Минем иҗатым




“Су буенда”




Математик әкият



Кипкән үсемлекләрдән аппликация



Пожар куркынычсызлыгы



Мамык дискларыннан аппликация



Оригами



Фольгадан аппликация

# Минем уңышларым

| Фәннәр | 2 класс<br>1чир. | 2чир. | 3чир. |
|---|---|---|---|
| Русский язык | 5 | 5 | 5 |
| Литературное чтение | 5 | 5 | 5 |
| Математика | 5 | 5 | 5 |
| Әйләнә-тирә дөнья | 5 | 5 | 5 |
| Технология | 5 | 5 | 5 |
| Иностранный язык | 5 | 5 | 5 |
| Музыка | 5 | 5 | 5 |
| Рәсем сәнгате | 5 | 5 | 5 |
| Әдәби уку | 5 | 5 | 5 |
| Татар теле | 5 | 5 | 5 |
| Физик культура | 5 | 5 | 5 |


Похвальный лист

Бүләкләнә
2015/2016 нчы уку елының
I яртыеллыгын „5" билге-
ләренә тәмамлаган
МББУ „Күнгер урта мәк-
тәбенең 2 нче сыйныф
укучысы Рамазанова Чул-
пан Фоатовна
Мәктәп директоры
В.Г. Галеев

МБОУ „Кулунурская СОШ"

| № | | год |
|---|---|---|
| 1 | Диплом I степени открытого межрегионального интеллектуального турнира способностей | 2014 |
| 2 | Диплом II степени открытого межрегионального интеллектуального турнира способностей | 2014 |
| 3 | Благодарственное письмо за активное участие в районном конкурсе “Әнием-күңелем түрендә” | 2014 |
| 4 | Диплом победителя в международной дистанционной олимпиаде по татарскому языку | 2014 |
| 5 | Диплом участника во Всероссийском творческом конкурсе “Пластилиновая фантазия” | 2014 |
| 6 | Диплом победителя на международной олимпиаде по татарскому языку | 2015 |
| 7 | Диплом за успешное прохождение базового онлайн курса Учи.ру по математике | 2015 |
| 8 | Диплом победителя на открытой Московской онлайн –олимпиаде по математике | 2015 |
| 9 | Похвальный лист МББОУ “Кугунурская СОШ” за хорошую учебу | 2015 |
| 10 | Грамота МБББУ “Куныр урта мәктәбе” математик уен-ярышта 1 нче урын | 2016 |
| 11 | Грамота МБББУ “Куныр урта мәктәбе” “математик әкият” язу номинациясендә 1 нче урын | 2016 |
| 12 | Сертификат участника в онлайн- олимпиаде по математике от Учи.ру | 2016 |
| 13 | Грамота МБББУ “Куныр урта мәктәбе” , “ Гаилә- тормыш нигезе” исемендәге бәйгедә “Алтын куллы гаилә” номинациясендә җиңүче | 2016 |
| 14 | Диплом победителя муниципального этапа республиканского конкурса XVIII Международного фестиваля «Детство без границ» 2 место | 2016 |



ДИПЛОМ
ПОБЕДИТЕЛЯ
МЕЖДУНАРОДНОЙ ОЛИМПИАДЫ
ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ «ТатарТеле.ИНФО»
НАГРАЖДАЕТСЯ
Рамазанова Чулпан Фоатовна
ученик(ца) 1 класса
МБОУ «Кугунурская СОШ»
село Кугунур, Республика Татарстан
М.А. Ермаков
Руководитель проекта
«ТатарТеле.ИНФО»
09.03.2015
Международная дистанционная олимпиада по татарскому языку для школьников Российской Федерации и зарубежных стран «ТатарТеле.ИНФО» http://www.tatartele.info/



МЕЖДУНАРОДНАЯ ДИСТАНЦИОННАЯ ОЛИМПИАДА ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ ДЛЯ УЧАЩИХСЯ 2-4 КЛАССОВ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ УЧРЕЖДЕНИЙ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ И ЗАРУБЕЖНЫХ СТРАН «ТАТАРТЕЛЕ.ИНФО»
ДИПЛОМ
ПОБЕДИТЕЛЯ
НАСТОЯЩИМ ДИПЛОМОМ НАГРАЖДАЕТСЯ ПОБЕДИТЕЛЬ ОЛИМПИАДЫ
Рамазанова Чулпан Фоатовна
ученик(ца) 2 класса
МБОУ «Кугунурская СОШ»
Село Кугунур Балтасинского муниципального района, Республика Татарстан
язык обучения: Татарский
МЕЖДУНАРОДНАЯ ДИСТАНЦИОННАЯ ОЛИМПИАДА ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ ДЛЯ УЧАЩИХСЯ 2-4 КЛАССОВ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ УЧРЕЖДЕНИЙ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ И ЗАРУБЕЖНЫХ СТРАН ПРОВОДИЛАСЬ С 1 СЕНТЯБРЯ ПО 22 ДЕКАБРЯ 2014 ГОДА НА ДИСТАНЦИОННО-ОБРАЗОВАТЕЛЬНОМ ПОРТАЛЕ «ТАТАРТЕЛЕ.ИНФО»
Автор проекта ТатарТеле.ИНФО
М.А. Ермаков



МИНОБР.ОРГ
Моё интернет образование
ДИПЛОМ
участника конкурса
Чулпан Рамазанова, 1 класс
Всероссийский творческий конкурс
"Пластилиновая фантазия"
проходил в период с 05 окт. 2014 года по 01 дек. 2014 года на образовательном портале Минобр.орг
01 дек. 2014
Главный редактор А. Белова
г. Санкт-Петербург


ДИПЛОМ
награждается
Рамазанова Чулпан
ученица МБОУ «кугунурская СОШ»
(рук. Файзрахманов Р.Р.)
занявшая II место в муниципальном этапе республиканского конкурса рисунков "Сказки народов мира", XVIII Международного фестиваля «Детство без границ» в младшей возрастной категории.
Начальник МКУ «Управление образования Балтасинского районного исполнительного комитета»
А.Ю.Закиева
приказ № 211 от 04.03.2016


Олимпиада «Плюс»
III Открытая Московская онлайн-олимпиада по математике
№258-336241
ДИПЛОМ ПОБЕДИТЕЛЯ
Награждается
Рамазанова Чулпан
ученица 2-го класса
МБОУ "Кугунурская СОШ"
Председатель Оргкомитета олимпиады
Директор Центра Педагогического Мастерства
И.В. Ященко
Председатель жюри
Е.М. Кац
UCHi.RU


№ 0352568
ДИПЛОМ
награждается
Чулпан Рамазанова
За успешное прохождение базового онлайн курса Учи.ру по математике 2 класса
Иван Владимирович Коломоец
Руководитель образовательной платформы «Учи.ру»
UCHi.RU


Благодарственное письмо
награждается
Рамазанова Чулпан
учащаяся МБОУ
„Кугунурская СОШ"
за активное участие
в районном семейном конкурсе фотографий
«Әнием – күңелем түрендә»
Начальник отдела социальной защиты МТЗиСЗ РТ в Балтасинском муниципальном районе
А. Ф. Гатиятуллина
2014 год


UCHi.RU

«Дино-олимпиада»

Первая онлайн-олимпиада по математике от Учи.ру

СЕРТИФИКАТ УЧАСТНИКА

Награждается

Чулпан Рамазанова

ученица 2-го класса

Генеральный директор «Учи.ру»

И. В. Коломоец

Февраль 2016 г.


Грамота

Бүләкләнә

Балтач муниципаль районы МБББУ "Куныр урта мәктәбе"нең II класс укучысы


Рамазанова Чулпан Фәрит кызы

математик уен – ярышта

I урын алган өчен

Мәктәп директоры В. Г. Галеев

28. 01. 2016


Грамота

Бүләкләнә

«Математик җыят» язу номинациясендә I урын алган өчен МБББУ «Куныр урта мәктәбе»нең II сыйныф укучысы Рамазанова Чулпан

30.01.16

Мәктәп директоры В.Г. Галеев


ТАТАРСТАН

Грамота

Бүләкләнә

«Гаилә – тормыш нигезе» исеме белән үткәрелгән иҗади бәйгедә «Алтын куллы гаилә» номинациясендә җиңүче Рамазановлар гаиләсе

Мәктәп дирекциясе

7 март. 2016


Факультет повышения квалификации и профессиональной переподготовки ФГБОУ ВПО «Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов»

ОТКРЫТЫЙ МЕЖРЕГИОНАЛЬНЫЙ ТУРНИР СПОСОБНОСТЕЙ

РостОК Intellect Ум

ДИПЛОМ

I степени

открытого межрегионального интеллектуального турнира способностей "РостОК-IntellectУм" для детей старшего дошкольного возраста

НАГРАЖДАЕТСЯ

Чулпан Рамазанова

МБДОУ детский сад "Карлыгач" Татарстан, Балтасинский район р-н, с. Кугунур

Председатель Оргкомитета И.М.Корнюшина

2014 год

III-ИД-016856


Факультет повышения квалификации и профессиональной переподготовки ФГБОУ ВПО «Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов»

ОТКРЫТЫЙ МЕЖРЕГИОНАЛЬНЫЙ ТУРНИР СПОСОБНОСТЕЙ

РостОК UnikУм

ДИПЛОМ

II степени

открытого межрегионального интеллектуального турнира способностей "РостОК-UnikУм" для детей старшего дошкольного возраста


НАГРАЖДАЕТСЯ

Чулпан Рамазанова

МБДОУ "Кугунурский детский сад" Татарстан, Балтасинский р-н, с. Кугунур

Председатель Оргкомитета И.М.Корнюшина

2014 год


ЗНАТОК РУССКОГО ЯЗЫКА

2014

ГРАМОТА

Награждается

Рамазанова Чулпан

за активное участие в интеллектуальной игре

«Знатоки русского языка»

Алфавит

А Б В Г Д Е Ё

Ж З И Й К Л

М Н О П Р С Т

У Ф Х Ц Ч Ш

Щ Ъ Ы Ь Э Ю Я

# Минем хыялларым

Хыялсыз кеше- канатсыз кош буладыр ул. Һәркемнең дә хыялы, алга планнары бардыр. Мин дә уйланырга бик яратам.

Иң беренче- барлык туганнарым да сау-сәламәт , озын гомерле булсын иде.

Икенчедән , дөньяда сугышлар булмасын, һәр баланың әти-әнисе булсын.

Минем мәктәпне яхшы билгеләргә генә укып бетерәсем килә. Шуңа күрә бар көчемне куеп һәр дәрескә ныклап әзерләнеп йөрим. Өстәмә материал да кулланырга яратам.

Мәктәпне тәмамлагач үзем башкара алырлык һөнәр сайларга кирәк.

Хыяллар күп инде ул. Гөлләрне дә бик яратам, тәрәзә төбе, өй тутырып гөлләр үстерәбез әнием белән.

Кешеләргә шатлык биреп, гөлләр үстереп сатучы булсаң да яхшы.

Кем булырга? Югалып калдым, һөнәр сайлау бит ул – бик авыр һәм җаваплы. Дөньяда бик күп һөнәрләр бар.

Уйладым, уйладым да шундый фикергә килдем: укытучы булам. Укытучы һәрбер баланы укырга, язарга өйрәтә.

Укытучы булу җиңел түгелдер. Моның өчен бик күп белергә, балаларны яратырга кирәк.

Укытучы – иң мактаулы хезмәт. Укытучыдан башка беркем дә һөнәргә өйрәнә алмый. Алар әле һөнәр генә түгел, ә тәрбия дә бирәләр. Ә мин нинди укытучы булыр идем соң?

Укытучы булсам, мин дәресләрне кызыклы, балалар сулыш алырга да онытып, кызыксынып, игътибар белән тыңларлык итеп үткәрер идем.

Мин һәр укучының партасында компьютер торуын булдырыр идем һәм күпчелек биремнәрне өйрәтүче программалар рәвешендә бирер идем. Ә билгеләр икәү генә булыр иде: "үти алган" һәм "әлегә йомшаграк".


Менә шундый укытучы булыр идем мин!


Мин – укытучы
!


Бу нинди сан?


Энем, сеңелләремне
укытам


Эх, гөлләрем!


Яратам, гөлләремне.


Су сибим үзегезгә.

# Эчтәлек


| | |
|---|---|
| 1 | *Титул бите* |
| 2 | *“Минем әйләнә-тирәм”* |
| 3 | *“Минем җәмәгать эшчәнлегем”* |
| 4 | *“Минем иҗатым”* |
| 5 | *“Минем уңышларым”* |
| 6 | *“Киләчәккә планнарым”* |